МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.06.2021 г.Казань № 388

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 25 июнендә 7763 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ びуларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 №484, 16.08.2019 №624, 14.11.2019 №1023, 18.06.2020 №436, 27.07.2020 №536, 24.09.2020 №669, 18.12.2020 №876 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.06.2021 №388 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

3.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза һәм документлар пакеты алынган көннән соң бер эш көне эчендә дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органнардан, муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнардан, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан ведомстволар арасында мәгълүмат хезмәттәшлеге кысаларында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле, гражданин (законлы вәкил), башка гражданнар,дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылмаган, әлеге Регламентка 13-23 кушымталарда күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр соратып алына.»;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән раслангын Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) 2 нче кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча

дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Гражданинны халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| Т/с | Документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Бирелгән көненнән башлап документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе* | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | белешмәдә күрсәтелгән |
| 2. | Вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар ** | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, документлар бирүгә вәкаләтле булган органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

«*» - инвалидларның федераль реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта инвалидларга бирелә;

«**» - гариза вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Гражданинны картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларда стационар формада социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм

социаль яклау министрлыгының территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| Т/с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе* | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | белешмәдә күрсәтелгән |
| 2. | Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе** | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 3. | Административ күзәтчелек билгеләү турында суд карары күчермәсе ** | суд органнары | законнар нигезендә |
| 4. | Административ күзәтчелек билгеләү турында тамгасы белән, төзәтү учреждениесеннән азат ителү турындагы белешмәнең күчермәсе ** | төзәтү учреждениесе | законнар нигезендә |
| 5. | Төзәтү учреждениесе хакимияте тарафыннан бирелгән, сайланган яшәү урынына барырга чыгу яисә, килү вакытын күрсәтеп, килү турында күрсәтмә күчермәсе ** | төзәтү учреждениесе | законнар нигезендә |
| 6. | Гражданинны административ күзәтчелекне гамәлгә ашыру өчен исәпкә кую турында белешмәләр ** | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 7. | Вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар *** | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, документлар бирүгә вәкаләтле булган | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | органнар (оешмалар) | |

«*» - инвалидларның федераль реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта инвалидларга бирелә;

«**» - ирektән мәхрүм итү урыннарын чыгарыла торган яисә чыгарылган затлар исәбендәге, Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга карата административ күзәтчелек билгеләнгән гражданнар өчен гариза биргәндә тапшырыла;

<***> - гариза вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.»;

Регламентка 4 нче кушымтада:

2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

5 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

Регламентка 5 нче кушымтада 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка 6 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт
күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану
һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең
хосусый программасын төзү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Гражданинны инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплексلы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| Т/с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документ күчермәсе * | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалид баланы тернәкләндерү буенча хосусый | федераль дәүләт медик-социаль экспер- | инвалидны (инвалид баланы) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | программа күчермәсе (2011 елның 30 октябренә кадәр Татарстан Республикасында ХТП эшләнгән һәм тапшырылган яисә Россия Федерациясенең башка субъектына эшләнгән һәм тапшырылган инвалидлар (инвалид балалар өчен) яисә 2016 елның 01 гыйнварыннан башлап Россия Федерациясенең башка субъектында эшләнгән һәм тапшырылган, инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча хосусый программа ** | тиза учреждениеләре | тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |
| Гражданинны халыкка комплексны хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла: | | | |
| 3. | Инвалид баланың законлы вәкиленең шәхесен, хокукларын таныклаучы документ күчермәсе (паспорт яисә балага опекун, попечительлек билгеләү турында, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында карар) *** | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 4. | Инвалид баланың мәнфәгатьләрен күрсәтү һәм яклау буенча билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе күчермәсе **** | Россия Федерациясе Граждан кодексының 185.1 статьясында һәм Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 53 статьясында күрсәтелгән нотариаль контора яисә оешма һәм учреждениеләр | ышаныч кәгазендә күрсәтелә торгана |
| 5. | Вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар ***** | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, документ- | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | лар бирүгә вәкаләтле булган органнар (оешмалар) | |

«*» - балигълык яшенә җитмәгәннәрне мохтаҗ буларак таныганда тапшырыла;

«**» - инвалидларның (инвалид балаларның) федераль реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта инвалидларга бирелә;

«***» - инвалид баланы озата йөрүче, аның законлы вәкиле булган зат өчен тапшырыла;

«****» - инвалид баланы озата йөрүче, аның законлы вәкиле исеменнән гамәл кылучы зат өчен тапшырыла;

«*****» - гариза вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.»;

Регламентка 7 нче кушымтада:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе – бала тууны теркәү чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан башкарылган очракта. | документлар бирү өчен вәкаләтле органнар (оешмалар) | 14 яшенә җиткәнче»; |

7 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

9 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

Регламентка 8 нче кушымтада 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка $8^1$ кушымтада:

3 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

4 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

Регламентка 10 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта

Гражданинны инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә ярымстационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча

Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| Т-с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1. | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документ күчермәсе * | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалид бала мәнфәгатләрендә эш итү өчен ышаныч кәгазе күчермәсе | законлы вәкил тарафыннан рәсмиләштерелә | ышаныч кәгазендә күрсәтелә торган яисә, ышаныч кәгазенең гамәлдә булу вакыты күрсәтелмәсә, 1 ел |
| 3. | Инвалид баланы тернәкләндерү буенча хосусый программа күчермәсе (2011 елның 30 октябренә кадәр Татарстан Республикасында ХТП эшләнгән һәм тапшырылган яисә Россия Федерациясенең башка субъектына эшләнгән һәм тапшырылган инвалидлар (инвалид балалар өчен) яисә 2016 елның 01 гыйнварыннан башлап Россия Федерациясенең башка субъектында эшләнгән һәм тапшырылган, инва- | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | лидны (инвалид баланы) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча хосусый программа ** | | |
| Гражданинны халыкка комплекслы хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла: | | | |
| 4. | Мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләре *** | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, документлар бирүгә вәкаләтле булган органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

«*» - документлар балигълык яшенә җитмәгәннәрне мохтаҗ буларак тану өчен тапшырыла;

«**» - документ, инвалидларның федераль реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта, инвалидларны (инвалид балаларны) мохтаҗ буларак тану өчен тапшырыла;

«***» - гариза мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.»;

Регламентка $11^1$ кушымтада:

таблица исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга көндез килеп тору бүлекчәләрендә өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбия кылу системасын оештыру буенча 2020-2022 елларда сынау проектында катнаша торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге»

3 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

«<***> – өлкән яшьтәге гражданнарга бирелә.» астөшермәсен үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка 13 нче кушымтада:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1. | Гражданинның даими яшәү урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар | вәкаләтле орган | законнар нигезендә»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында белешмәләрне үз эченә алган документлар | | |

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «5. | Гражданинның сәламәтлеге торышын, ятлар каравына мохтаҗ булуын сыйфатлаучы, үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшенә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларын тәэмин итү сәләтен тулысынча яисә өлешчә югалтуын раслаучы медицина документлары * | медицина оешмалары | медицина документларында күрсәтелә торган»; |

түбәндәге эчтәлекле астөшермә өстәргә:

«* - инвалидлыгы булмаган гражданнарга тапшырыла яки сорала.»;

Регламентка 14 нче кушымтада:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | Гражданинның яшәгән урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ | вәкаләтле орган | 30 көн»; |

түбәндәге эчтәлекле 7, 8 пунктларын өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «7. | Гражданинның сәламәтлек торышын, даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ булуын сыйфатлаучы, үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшенә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларын тәэмин итү сәләтен өлешчә югалтуын раслый торган медицина документлары **** | медицина оешмалары | медицина документларында күрсәтелә торган |
| 8. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыклары булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә»; |

түбәндәге эчтәлекле астөшермә өстәргә:

«**** - инвалидлыгы булмаган өлкән гражданнарга тапшырыла яки сорала.»;

Регламентка 15 нче кушымтада:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | Гражданинның яшәгән урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ | вәкаләтле орган | 30 көн»; |

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «7. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыклары булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә; |

түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «8. | Табиб-психиатр катнашындагы табиблар комиссиясенең социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затта аның социаль хезмәт күрсәтүнең башка стационар учреждениесендә булу мөмкинлеген юкка чыгара торган психик тайпылышлар булуы турында (законнарда билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дин танылган социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затлар өчен); суд каршында аны эшкә сәләтсез буларак тану мәсьәләсен күтәрү өчен нигезләр булмавы турында (социаль хезмәтләр күрсәтелә торган эшкә сәләтле зат өчен) белешмәләрне үз эченә алган бәяләмә | медицина оешмалары | законнар нигезендә»; |

Регламентка 16 нчы кушымтага түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыклары булмавы турында бәяләмә | медицина оешмалары | законнар нигезендә»; |

Регламентка 17 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 17 нче кушымта

Гражданинны инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы

муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар исемлеге

| Т/с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү буенча Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда эшләнгән һәм бирелгән хосусый программа күчермәсе яисә инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча Татарстан Республикасында 2016 елның 01 гыйнварыннан бирелгән хосусый программадан өземтә күчермәсе * | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |
| 2. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә |
| 3. | Үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшькә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларны тәэмин итү сәләтен өлешчә югалтуны раслаучы медицина | медицина оешмалары | медицина документларында күрсәтелә торган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | документлары ** | | |
| 4. | Стационар социаль хезмәтләр алу өчен медицина каршылыклары булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |
| Гражданинны халыкка комплексны хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаж буларак тану өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла яки соратыла: | | | |
| 5. | Гражданинның яшәгән урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ | вәкаләтле орган | 30 көн |
| 6. | Мөрәҗәгать итүченең даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәгән затларны аның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслый торган документларның күчермәләре *** | вәкаләтле орган | законнар нигезендә |

«*» - инвалидлар (инвалид балалар) өчен;

«**» - халыкка комплексны социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен килгән, инвалидлыгы булмаган өлкән гражданнар өчен тапшырыла яки соратыла;

«***» - 1100 номерлы Тәртипнең 5.2.3 пунктының «а»-«е» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен соратылмый.»;

Регламентка 18 нче кушымтада:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Баланың туу турындагы таныклыгы күчермәсе (14 яшьтән кечерәк яисә паспорты булмаган балалар өчен) | гражданлык хәле актларын теркәү органы | 14 яше тулганчы»; |

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Сәламәтлек саклау учреждениесенең ата-ананы яисә законлы вәкилне (бердәнбер) госпитальләштерү зарурлыгы | сәламәтлек саклау учреждениесе | белешмәдә билгеләнгән датага кадәр»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында белешмә | | |

Регламентка 19 нчы кушымтада 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1. | Гражданинның яшәгән урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ * | вәкаләтле орган | 30 көн»; |

Регламентка 19[1] кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2, 3 пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Стационар социаль хезмәтләр алу өчен медицина каршылыклары булмавы турында бәяләмә | медицина оешмалары | сәламәтлек торышы турында белешмәдә күрсәтелгән |
| 3. | Интеллекты җиңелчә яки өлешчә бозылганлыгын (МКБ-10: F70, F71 буенча диагноз) яисә югары дәрәҗәле функциональ аутизм (Аспергер синдромы) (МКБ-10: F84.5 буенча диагноз) булуын, шулай ук эчкечелек һәм наркотик бәйлелек һәм качып китүгә омтылышлар булмавын раслый торган белешмә | Татарстан Республикасы медицина оешмалары, психоневрологик интернатлар (социаль хезмәт күрсәтелә торган затлар өчен тиешле психоневрологик интернат) | законнар нигезендә»; |

Регламентка 20 нче кушымтада 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | Гражданинның яшәгән урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ** | вәкаләтле орган | 30 көн»; |

Регламентка 21 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү

буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
21 нче кушымта

Гражданинны халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар исемлеге

| Т/с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр алучының яшәгән урынын раслаучы документ күчермәсе (1101 номерлы Тәртипнең 3.1.3 пунктында каралган очрактан тыш) | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, суд | законнар нигезендә |
| 2. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документ күчермәсе * | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 3. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү буенча Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда эшләнгән һәм бирелгән хосусый программа күчермәсе яисә инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча Татарстан | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасында 2016 елның 01 гыйнварыннан бирелгән хосусый программадан өземтә күчермәсе ** | | абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |
| 4. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә |
| 5. | Үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшькә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларны тәэмин итү сәләтен өлешчә югалтуны раслый торган медицина документлары *** | медицина документлары | медицина документларында күрсәтелә торган |
| 6. | Үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшькә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларны тәэмин итү сәләтен югалтуны раслый торган медицина документлары **** | медицина документлары | медицина документларында күрсәтелә торган |
| Гражданинны халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла яки соратыла: | | | |
| 7. | Мөрәҗәгать итүче белән берлектә аның даими яшәү урыны буенча яшәүче затларны аның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслаучы документлар күчермәсе ***** | вәкаләтле орган | законнар нигезендә |
| 8. | Гражданинның яшәгән урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар ту- | вәкаләтле орган | 30 көн |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | рындагы белешмәләрне үз эченә алган документ ****** | | |
| 9. | Мөрәҗәгать итүченең ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә кабул ителгәндә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлек рәвештә хокуклы булуын раслый торган документ күчермәсе ****** | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелә торган |

«*» документлар балигълык яшенә җитмәгәннәрне мохтаҗ буларак тану өчен тапшырыла яки соратыла;

«**» инвалидларны (инвалид балаларны) мохтаҗ буларак тану өчен тапшырыла яки соратыла;

«***» - халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен килгән, инвалидлыгы булмаган өлкән гражданнар өчен тапшырыла яки соратыла;

«****» - сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен килгән, инвалидлыгы булмаган 4 яшькә кадәрге балалар өчен тапшырыла яки соратыла;

«*****» 1101 номерлы Тәртипнең 3.2.4 пунктының «а»-«д» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен соратылмый.

«******» - стационар формада социаль хезмәт күрсәтүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле хокукка ия булган ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1101 номерлы Тәртип нигезендә бушлай нигездә социаль хезмәтләр күрсәтү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла яки соратыла.»;

$22^1$ кушымтада:

таблица исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга көндез килеп тору бүлекчәләрендә өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбия кылу системасын оештыру буенча 2020-2022 елларда сынау проектында катнаша торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану өчен кирәкле, яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документлар исемлеге»;

түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Өлкән кешенең хәтер (деменция, картларча | медицина оешмалары | законнар нигезендә»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | астения) яки когнитив җитешсезлекләр булуын раслый торган белешмә яки яшенә бәйле рәвештә төп яшәеш ихтыяҗларын тәэмин итүдә өлешчә мөмкинлеген югалтуы турында белешмә * | | |

түбәндәге эчтәлекле «*» астөшермә өстәргә:
«* - өлкән яшьтәге гражданнарга тапшырыла.».